КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 июнь г.Казань № 512

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 карары белән расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары экспертизасын үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан кабул ителүче (чыгарылучы) Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив хокук актларының һәм норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын ачык бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1182 карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 июль, 511 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 948 нче; 2016 ел, 4 июль, 457 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актлары экспертизасын үткәрү тәртибенә, 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми

принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3-3 статьясы, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертизаны уздыру тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы законнары проектларының, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарының Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралган эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа яисә үзгәртә торган, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа каралган бурычларны билгели торган норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрүгә бәйле, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) бозган өчен элек билгеләнгән җаваплылыкны үзгәртә яисә юкка чыгара торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, түбәндәгеләрдән тыш**:**

а) төбәк салымнарын, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган Татарстан Республикасы закон проектлары;

б) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

в) продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) җайга салучы бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сәүдә өстәмәләре (өстәмә хаклар) өлкәсендә бәя кую тәртибен билгели торган федераль законнар нигезендә дәүләт җайга салынырга тиешле продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) җайга салучы бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сәүдә өстәмәләре (өстәмә хаклар) билгеләүче, үзгәртүче, юк итүче Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектлары;

г) гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорга табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектлары,

шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарының норматив хокукый актларына (алга таба – норматив хокукый актлар) экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

Норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының

һәм Татарстан Республикасы бюджетының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә этәрә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин